КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 15 апрель г.Казань № 412

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә 2024 елның 21 декабрендә пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме нәтиҗәсендә мөлкәте югалган яисә зыян күргән физик һәм юридик затларга финанс ярдәме күрсәтү турында» 2025 ел, 30 октябрь, 879 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә 2024 елның 21 декабрендә пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме нәтиҗәсендә мөлкәте югалган яисә зыян күргән физик һәм юридик затларга финанс ярдәме күрсәтү турында» 2025 ел, 30 октябрь, 879 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә 2024 елның 21 декабрендә пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме нәтиҗәсендә мөлкәте югалган яисә зыян күргән физик һәм юридик затларга финанс ярдәме күрсәтү тәртибенең 13 пункты үз көчен югалткан дип танылырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына 2024 елның 21 декабрендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме нәтиҗәсендә автомобиль транспорты югалган яки зыян күргән  финанс ярдәме алуга мохтаҗ гражданнарга һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә 2024 елның 21 декабрендә пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме нәтиҗәсендә мөлкәте югалган яисә зыян күргән физик һәм юридик затларга финанс ярдәме күрсәтү турында» 2025 ел, 30 октябрь, 879 нчы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә 2024 елның 21 декабрендә пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме нәтиҗәсендә мөлкәте югалган яисә зыян күргән

физик һәм юридик затларга финанс ярдәме күрсәтү тәртибе (алга таба - Тәртип) нигезендә финанс ярдәме күрсәтергә һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына финанс ярдәмен соңгы түләү башкарылган көннән соң 30 көн эчендә финанс ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисапны Тәртипкә 5 нче кушымта нигезендәге форма буенча тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына 2024 елның 21 декабрендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме нәтиҗәсендә автомобиль транспорты югалган яки зыян күргән финанс ярдәме алуга мохтаҗ гражданнар һәм юридик затлар исемлеген тапшырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин